**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге составына керүче Бикчурай авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

4 декабрь, 2021 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Башлыгының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Зур Мәшләк, Бикчурай, Югары Мәшләк авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2021 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы карары нигезендә, 2021 елның 4 декабрендә узган гражданнар җыенының 1 нче номерлы йомгаклау беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Бикчурай авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 1. 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Зур Мәшләк, Югары Мәшләк һәм Бикчурай авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлар, балачактан инвалид, 1 группа инвалидлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә. Тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Бикчурай торак пунктын зират белән тоташтыручы күперне ремонтлау;
- Зур Мәшләк, Югары Мәшләк, Бикчурай авылларында энергияне саклаучы яктырткычларына хезмәт күрсәтү;
- су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү ;
- кышын Зур Мәшләк авыл җирлегенең Зур Мәшләк, Югары Мәшләк, Бикчурай торак пунктларында урамнарның йөри торган өлешләрен карап торуга (кардан арындыруга);

- Зур Мәшләк авылының О.Кошевой урамына 150 метр су трубасы сузуга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авылы, Школьная урамы, 13А йорт; Югары Мәшләк авылы, Нариманова урамы, 24а йорт; Бикчурай авылы, М.Горький урамы, 50 А йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче –
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге Башлыгы М.Г.Заһидуллин